СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 2

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советы КАРАРЫ**

**«2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллардагы план чорына Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджеты турында»**

1 Маддә

1.2019 елга Минзәлә муниципаль район бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Минзәлә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме 835 246 ,1 мең сум тәшкил итә;

2) Минзәлә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 835 246 ,1 мең сум.

3) Минзәлә муниципаль районы бюджеты дефициты 0 мең сум.

2. 2020 һәм 2021 елларга Минзәлә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2020 елга Минзәлә муниципаль район бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме 837339,3 мең сум һәм 2021 елга 831 858,9 мең сум;

2) Минзәлә муниципаль район бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2020 елга 837339,3 мең сум, шул исәптән, шартлы рәвештә расланган чыгымнар 15543,9 мең сум һәм 2021 елга 831858,9 мең сум, шул исәптән, шартлы рәвештә расланган чыгымнар 30822,4 мең сум .

3) Минзәлә муниципаль район бюджеты дефициты 0 мең сум.

3.Гамәлдәге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларда план чорына Минзәлә муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын расларга.

2 маддә

1. 2020 елның 1 гыйнварына торышы буенча Минзәлә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;

2. 2021 елның 1 гыйнварына торышы буенча Минзәлә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;
3. 2022 елның 1 гыйнварына торышы буенча Минзәлә муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән, муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;
4. Минзәлә муниципаль районы муниципаль бурычының чикләнгән күләмен түбәндәгечә билгеләргә:
   2019 елда - 0 мең сум;
   2020 елда 0 мең сум;
   2021 елда 0 мең сум.

3 Маддә
Гамәлдәге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларда план чорына керемнәрнең фаразланган күләмен Минзәлә муниципаль район бюджетында исәпкә алырга.
4 Маддә
Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 маддәсе, 2 пункты нигезендә, гамәлдәге Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларда план чорына Минзәлә муниципаль районы бюджет системасының бюджетлар арасында керемнәрне бүлешү нормативларын расларга.
5 Маддә
2019 елда һәм 2020 һәм 2021 елларда план чорына Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына кертү 2018, 2019, 2020 еллар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре табышына кагылышлы салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң 2019, 2020, 2021 елларның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарылуын билгеләргә.

6 Маддә
1.Гамәлдәге Карарның 4 нче кушымтасы нигезендә Минзәлә муниципаль район бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген расларга.
2. Гамәлдәге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә Минзәлә муниципаль район бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген расларга.

7 маддә
1. Гамәлдәге Карарның 6 нче кушымтасы нигезендә, 2019 елга һәм2 020 һәм 2021 елларда план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан маддәләр, чыгымнар төре группалары буенча бюджет ассигнованиеләренә бүлгәләүне расларга.

2. Гамәлдәге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә, 2019 елга һәм2 020 һәм 2021 елларда план чорына Минзәлә муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын расларга.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетының җәмәгать норматив бурычларын башкаруга юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2019 елга 6822,2 мең сум, 2020 елга 6839,2 мең сум, 2021 елга 6855,2 мең сум күләмендә расларга.
4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район бюджетының җәмәгать норматив бурычларын башкаруга юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2019 елга 6822,2 мең сум, 2020 елга 6839,2 мең сум, 2021 елга 6855,2 мең сум күләмендә расларга.

8 Маддә

Гамәлдәге Карарның 8 нче кушымтасы нигезендә җирлекләрнең бюджет белән тәмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен 2019 елга 62111,1 мең сум, 2020 елга 61781,5 мең сум, 2021елга 61569,7 мең сум күләмендә расларга.

9 Маддә

Гамәлдәге Карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә хәрби комиссариат булмаган территорияләрдә беренчел хәрби учетка куюны башкару буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга җирлек бюджетларына субвенцияләр күләмен 2019 елга 1641,7 мең сум, 2020 елга 1647,3 мең сум, 2021 елга 1707,9 мең сум күләмендә расларга.

10 Маддә

Гамәлдәге Карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен 2019 елга 19800,0 мең сум, 2020 елга 20800,0 мең сум, 2021елга 21400,00 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2019, 2020 һәм 2021 елларда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының гомуми кулланудагы юлларында юл эшләре муниципаль Программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлтергә.

11 Маддә

Гамәлдәге Карарның 11 нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 2019 елда 554 271,4 мең сум, 2020 елда 551 398,2 мең сум, 2021 елда 543 529,4 мең сум күләмендә Минзәлә муниципаль район бюджетында исәпкә алырга.

12 Маддә

1. Гамәлдәге Карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә бүленгәнчә, әзерләнгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне башкаруга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район бюджетына җирлек бюджетларыннан күчерелергә тиеш бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга;

- халыкның ялын оештыру мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруга 2019 елга 25 580,7 мең сум, 2020 елга 25 933,5 мең сум, 2021 елга 26 283,2 мең сум;

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмитякә ия булган автомобиль юлларына карата, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә башка вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен 2019 елга 13764,3 мең сум, 2020 елга 13764,3 мең сум, 2021 елга 13764,3 мең сум;
- муниципаль торак фондын төзү һәм тәртиптә тотуны оештыруга, торак төзелеше өчен шартлар тудыруга, муниципаль торак контролен башкаруга, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен тормышка ашыруга 2019 елга 6615,0 мең сум, 2020 елга 6615,0 мең сум, 2021 елга 6615,0 мең сум;
- 2019 елга бухгалтерлык учетын һәм исәбен алып бару өчен 2019 елга 3372,2 мең сум, 2020 елга 3454,0 мең сум, 2021 елга 3550,2 мең сум;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләрне урнаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тәртиптә тотуны да кертеп) - 2019 елга 1820,6 мең сум, 2020 елга 0 мең сум, 2021 елга 0 мең сум.
2. Тиешле җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына гамәлдәге маддәдә күрсәтелгән җирлек бюджетларында бюджетара трнасфертларны күздә тотарга.
3. 2019 елда һәм 2020 һәм 2021 елларда план чорында гамәлдәге маддәләрдә каралганча, Минзәлә муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетларыннан бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләргә бүленеп башкарылуын билгеләргә.

13 Маддә

1. Минзәлә муниципаль районының муниципаль хакимияте органнары 2018 елда һәм 2019 һәм 2020 елларда план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның хезмәткәрләре санының артуына китерүче карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.
2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2018 елда һәм 2019 һәм 2020 елларда план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның хезмәткәрләре санының артуына китерүче карарлар кабул итмәүләрен тәкъдим итәргә.

14 Маддә

1. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының казанчылык органнары килешүләр нигезендә Минзәлә муниципаль бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкаралар.
2. Минзәлә муниципаль район бюджетының 01.01.2019 елга калган 2018 елда түләү каралган муниципаль контрактлар шартлары буенча тәңгәл китерелергә тиеш булган товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә Минзәлә муниципаль район исеменнән төзелгән муниципаль контрактларны түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән

очракта, 2019 елда күрсәтелгән максатлар өчен тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

15 Маддә
Гамәлдәге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Совет рәисе А.Ф. Салахов